ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **КАРАР**

«18» май 2022 ел № 118

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тирсә авылының "Миләүшә» балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә бер мәктәпкәчә төркемне ябу турында

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы үтенечнамәсен карап, мәктәпкәчә яшьтәге балалар саны кимү сәбәпле, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хезмәт кодексына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елның 01 июненнән Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тирсә авылының "Миләүшә» балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә бер мәктәпкәчә төркемне ябарга.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тирсә авылының «Миләүшә» балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең штат саны турында» 2019 елның 08 маендагы 182 номерлы карары белщн расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тирсә авылының «Миләүшә» балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең штат санына, вазыйфаларның түбәндәге штат берәмлекләрен төшереп калдырып, үзгәрешләр кертергә:

2.1. вазыйфаларны бетерергә:

- «1,5» штат берәмлекләре санында «тәрбияче»;
- «0,25» штат берәмлекләре санында «укытучы-логопед»;
- «0,25» штат берәмлекләре санында «педагог-психолог»;
- «2» штат берәмлекләре санында «кече тәрбияче, тәрбияче ярдәмчесе»;
- «0,5» штат берәмлекләре санында «пешекче»;
- «0,5» штат берәмлекләре санында «пешекче ярдәмчесе».

3. Мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид балаларга белем бирү максатыннан кертергә:

3.1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең 7 нче санлы «Бәләкәч» балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениясендә түбәндәге штат берәмлеге вазыйфасын:
- «0,5» штат берәмлекләре санында «укытучы-логопед»;

3.2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең 1 нче санлы «Алтын ачкыч» балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениясендә түбәндәге штат берәмлеге вазыйфасын:
- «0,5» штат берәмлекләре санында «укытучы-логопед»;

3.3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең 4 нче санлы балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениясендә түбәндәге штат берәмлеге вазыйфасын:
- «0,5» штат берәмлекләре санында «укытучы-логопед»;

3.4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең 5 нче санлы балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениясендә түбәндәге штат берәмлеге вазыйфасын:
- «0,5» штат берәмлекләре санында «укытучы-логопед».

4. "Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе" муниципаль казна учреждениесе башлыгына әлеге карар буенча оештыру-штат чараларын үткәрүне тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга https://agryz.tatarstan.ru.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О. А. Баженовага йөкләргә.

Җитәкчесе **А.Э.Акбашев**